**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**27 октябрь 2022** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 27 октябрендә 09:00 сәгатьтә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Иске Эсләк урам яктырткычлары өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу, Иске Эсләк авылы килешүе буенча эш өчен түләү;
- Иске Эсләк авылында халыкны су белән тәэмин итү (килешү буенча ремонт, хезмәт күрсәтү, түләү, су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу);
- Иске Эсләк авылында юлларны кардан чистарту;
- Иске Эсләк авылында корыган агач-куакларны кисү һәм территориясен чистарту;
- Иске Эсләк авылында Үзәк һәм Мәктәп урамнарына вак таш сатып алу һәм җәйдерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 217 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 113 кеше, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 113 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Иске Эсләк урам яктырткычлары өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу, Иске Эсләк авылы килешүе буенча эш өчен түләү;

- Иске Эсләк авылында халыкны су белән тәэмин итү (килешү буенча ремонт, хезмәт күрсәтү, түләү, су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу);

- Иске Эсләк авылында юлларны кардан чистарту;

- Иске Эсләк авылында корыган агач-куакларны кисү һәм территориясен чистарту;

- Иске Эсләк авылында Үзәк һәм Мәктәп урамнарына вак таш сатып алу һәм җәйдерү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Әхмәтов Д.М.

Совет Старосляковского сельского поселения
Иске Эсләк авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002580